ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 март 2021 ел

№ 1871

Яр Чаллы шәһәре территориясендә хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү тәртибе хакында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда халыкка хәбәр итү системаларыннан файдалануга даими әзерлектә тору максатында, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү тәртибе турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Россия Федерациясе законнары нигезендә, потенциаль куркыныч һәм I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын эксплуатацияләүче оешма җитәкчеләренә локаль хәбәр итү системаларын файдалануга даими әзерлектә тотуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 18 мартындагы
1871 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү тәртибе турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда Яр Чаллы шәһәре халкына хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасы (алга таба – хәбәр итү системасы) билгеләнешен, составын, бурычларын һәм аны булдыру, камилләштерү (реконструкцияләү) һәм файдалануга даими әзерлектә тоту тәртибен билгели.

2. Хәбәр итү системасы гражданнар оборонасы белән идарә итү системаларының состав өлеше һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы булып санала (алга таба – ГТХТС).

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәгеләр булдырыла:

муниципаль дәрәҗәдә – җирле хәбәр итү системасы;

объект дәрәҗәсендә – локаль хәбәр итү системасы (потенциаль куркыныч һәм I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын эксплуатацияләүче оешмалар урнашкан районда).

2 бүлек. Хәбәр итү системасының билгеләнеше һәм төп бурычлары

4. Хәбәр итү системасы хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең идарә итү органнарына, гражданнар оборонасы көчләренә һәм чараларына, ГТХТС ның җирле звеносына һәм халыкка мәгълүмат һәм сигналларны үз вакытында җиткерүне тәэмин итү өчен билгеләнгән.

5. Хәбәр итү системасының төп бурычы булып мәгълүмат һәм хәбәр итү сигналларын түбәндәгеләргә җиткерүне тәэмин итү тора:

- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасының җитәкче составына һәм ГТХТС ның җирле звеносына;
- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә;
- Яр Чаллы шәһәре территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү өчен билгеләнгән һәм бүленгән (җәлеп ителгән), махсус әзерләнгән көчләргә һәм чараларга, гражданнар оборонасы көчләренә һәм чараларына;
- Яр Чаллы шәһәре территориясендә потенциаль куркыныч һәм I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын эксплуатацияләүче оешмаларның дежур-диспетчерлык хезмәтләренә;
- Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшәүче халыкка.

6. Халыкка хәбәр итү түбәндәгеләрне күздә тота:

- табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр (алга таба – ГТХ) килеп чыгу прогнозын яки фактын халыкка җиткерүне;

- табигый һәм техноген характердагы ГТХ килеп чыгу прогнозлары яки факты турында мәгълүмат алган вакыттан соңгы эш гамәлләре хакындагы рекомендацияләрне халыкка җиткерүне.

Халыкка мәгълүмат бирү түбәндәгеләрне күздә тота:

- табигый һәм техноген характердагы ГТХ килеп чыгу прогнозы яки факты турында мәгълүматлар бирүне;

- ГТХ үсеше, ГТХ масштаблары, ГТХ барышы һәм ГТХны ликвидацияләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне;

- табигый мохит һәм потенциаль-куркыныч объектларның торышы турында мәгълүмат бирүне;

- көтелгән гидрометеорологик, стихияле һәм башка табигать күренешләре турында мәгълүмат бирүне;

- халыкны системалы рәвештә ГТХны контрольдә тоту һәм ликвидацияләүне күзәтүче көчләр һәм чаралар тарафыннан үткәрелгән чаралар белән таныштырып торуны;

- халыкка ГТХ булу ихтималыннан саклану турында мәгълүмат җиткерүне.

7. Локаль хәбәр итү системасының төп бурычы булып мәгълүмат һәм сигналларны түбәндәгеләргә җиткерүне тәэмин итү тора:

- потенциаль куркыныч һәм I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын эксплуатацияләүче оешмаларның гражданнар оборонасының җитәкче составына һәм ГТХТС ның җирле звеносына;

- объектларның авария-коткару, шул исәптән махсуслаштырылган формированиеләренә;

- I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын эксплуатацияләүче оешма персоналына;

- гражданнар оборонасы белән идарә итү органнарының оператив дежур хезмәтләренә һәм ГТХТСка;

- локаль хәбәр итү системасы эшләгән зонада урнашкан оешма җитәкчеләренә һәм дежур-диспетчерлык хезмәтләренә;

- локаль хәбәр итү системасы эшләгән зонада яшәүче халыкка.

## 3 бүлек. Хәбәр итү системасыннан файдалану тәртибе

8. Халыкка хәбәр итүнең төп ысулы – элемтә челтәрләре буенча телевизион тапшырулар һәм радио тапшырулар программаларын тарату өчен мәгълүмат һәм хәбәр итү сигналлары бирү.

Мәгълүмат һәм хәбәр итү сигналлары бирү ГТХТС белән көндәлек идарә итү органнары тарафыннан элемтә челтәрләре буенча телевизион тапшырулар һәм радио тапшырулар программаларын тарату өчен элемтә операторларының радио тапшырулар һәм телевизион тапшырулар станцияләре һәм телерадиотапшырулар аша тапшыру программаларын туктатып торып гамәлгә ашырыла.

Дәвамлылыгы биш минуттан артмаган сөйләм мәгълүмат, кагыйдә буларак, халыкка, телерадиотапшырулар студиясеннән тапшыру программаларын туктатып торып тапшырыла. Сөйләм мәгълүматны өч тапкыр кабатлап тапшыру рөхсәт ителә.

Сөйләм мәгълүматны тапшыру, кагыйдә буларак, профессиональ дикторлар тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиеш, ә алар булмаган очракта – моңа вәкаләтле оешмаларның вазыйфаи затлары тарафыннан.

Кичектереп тору мөмкин булмаган искәрмә очракларда, кыска сөйләм мәгълүматларны турыдан-туры тапшыру юлы яки ГТХТС белән көндәлек идарә итү органнарының оператив дежур (дежур-диспетчерлык) хезмәтләре язмада турыдан-туры

эш урыннарыннан тапшыруы рөхсәт ителә.

Хәбәр итү максатында, ГТХТС белән даими эшләүче идарә итү органнары карары нигезендә, мәгълүмат һәм хәбәр итү сигналларын элемтә оешмалары дежур персоналының, элемтә операторларының эш урыннарыннан, радио тапшырулар һәм тапшыру станцияләренең элемтә чараларының хәбәр итү системаларында файдаланыла торган техник мөмкинлекләрен исәпкә алып тапшыру рөхсәт ителә.

9. ГТХТС белән көндәлек идарә итү органнары, мәгълүмат яки хәбәр итү сигналын алгач, аларны алуны раслыйлар, алынган мәгълүмат яки хәбәр итү сигналларын кичекмәстән идарә органнарына, гражданнар оборонасы көчләре һәм чараларына һәм ГТХТСка җиткерәләр.

10. Мәгълүмат яки хәбәр итү сигналларын бирү автоматлаштырылган режимда да, автоматлаштырылмаган режимда да гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Автоматлаштырылган режим төп режим булып санала, ул мәгълүмат яки хәбәр итү сигналларын идарә органнарына, гражданнар оборонасы көчләре һәм чараларына һәм ГТХТСка, халыкка циркуляр, төркемләп яки сайлап җиткерүне тәэмин итә.

Мәгълүмат яки хәбәр итү сигналларын идарә органнарына, гражданнар оборонасы көчләренә һәм чараларына һәм ГТХТСка, халыкка автоматлаштырылмаган режимда бирү Россия Федерациясенең гомуми файдаланудагы элемтә челтәре каналларына тапшыру вакытына сайлап, хәбәр бирү объектларына сайлап тоташтыру юлы белән җиткерелә.

11. Халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүнең өстәмә ысулы булып автоматлаштырылган система аша дистанцион идарә ителә торган электр сиреналары ярдәмендә «Һәркем игътибарына» сигналын бирү тора. Халык өчен сөйләм мәгълүмат гамәлдәге радио-, теле- һәм чыбыклы тапшырулар челтәрләре һәм тавышлы сирена җайланмалары буенча тапшырыла.

Моннан тыш, тавыш көчәйткеч системалар белән җиһазландырылган экстрен хезмәт автомашиналары, кул сиреналары һәм мегафоннар, шулай ук кәрәзле элемтә операторлары ресурсы (SMS-мәгълүмат бирү) җәлеп ителергә мөмкин.

12. Яр Чаллы шәһәре халкына хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасы электр сиреналары белән идарә ителә торган экстрен хәбәр итү комплекслы системасының аерылгысыз өлеше булып тора.

13. Хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасын эшләтүгә боерык түбәндәгеләр тарафыннан бирелә:

- муниципаль хәбәр итү системасына – Башкарма комитет Җитәкчесе – гражданнар оборонасы Җитәкчесе (яки аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан телдән боерык бирү юлы белән, кичекмәстән «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең кризислы хәлләрдә идарә итү үзәге» федераль казна учреждениесенә (алга таба – «Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча БИ КХИИҮ» ФКУ Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте аша мәгълүмат бирү юлы белән;

- Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча БИ КХИИҮ» ФКУ ның өлкән оператив дежурына яки аның вазыйфаларын башкаручы затка Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы рөхсәте белән, муниципальара (территориаль) дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләр куркынычы янаганда;

- локаль хәбәр итү системасына – потенциаль куркыныч һәм I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын эксплуатацияләүче оешма җитәкчесенә яки аның вазыйфаларын башкаручы затка.

14. Хәбәр итү системасын эшләтү буенча турыдан-туры эшләр ГТХТС белән көндәлек идарә итү органының дежур (дежур-диспетчерлык) хезмәтләре, элемтә оешмаларының дежурлык хезмәтләре, элемтә операторлары һәм хәбәр бирүне тәэмин итүгә җәлеп ителгән телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

15. Халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасын санкцияләнмәгән эшләтү

очраклары турында элемтә операторлары һәм телерадиотапшырулар оешмалары кичекмәстән ГТХТС белән даими эшләүче идарә итү органнарына хәбәр итәләр.

16. Халыкка үз вакытында һәм гарантияләнгән хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү өчен Яр Чаллы шәһәре территориясендә экстрен хәбәр итү зоналарында гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу яки килеп чыгу куркынычы янау турында Халыкка экстрен хәбәр итүнең комплекслы системасы (алга таба – ХЭХИКС) эшли.

ХЭХИКС Татарстан Республикасы хәбәр итү системасының элементы булып тора, шуңа күрә аны куллану тәртибе – барлык система өчен уртак.

Халыкка хәбәр итүнең ХЭХИКС элементлары белән иң беренче чиратта җиһазландырылырга тиешле экстрен зоналары (кеше тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыручы, аларда тиз тарала торган куркыныч табигать күренешләре һәм техноген процесслар килеп чыгуга дучар ителгән территорияләр) исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана.

## 4 бүлек. Хәбәр итү системасын камилләштерү һәм файдалануга әзерлектә тоту тәртибе

17. Хәбәр итү системасын даими әзерлектә тоту максатында Яр Чаллы шәһәре халкына хәбәр итүдә техник көчләр һәм чараларның техник торышын һәм куллануга әзерлеген тикшерү оештырыла, алар түбәндәгеләргә бүленә:

- читтәге хәбәр итү чараларын кабызып, хәбәр итү системасы әзерлеген комплекслы техник тикшерүләр һәм, тикшерү өчен, хәбәр итүче мәгълүмат сигналларын Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшәүче халыкка җиткерү (кимендә елга бер тапкыр үткәрелә);
- хәбәр итү системасын эшләтүгә әзерлекне читтәге хәбәр итү чараларын кулланмыйча техник тикшерүләр;
- хәбәр итү системасын ай саен планлы тикшерүләр;
- хәбәр итү системасын планнан тыш тикшерүләр.

18. Хәбәр итү системасын тикшерүләр составында Башкарма комитет, Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Татарстан Республикасы ГТХМ, «Таттелеком» ААҖ филиалы «Яр Чаллы ЗЭЭУ» вәкилләре булган, элемтә оешмалары һәм операторлары катнашындагы комиссия тарафыннан үткәрелә, ә телерадиотапшыру челтәрләре катнашындагы тикшерүләр, моннан тыш, – хәбәр бирүне тәэмин итүгә җәлеп ителгән телерадиокомпанияләр, предприятиеләр яки аларның филиаллары вәкилләре катнашында үткәрелә. Хәбәр итү системасын тикшерүләр үткәрү барышында хөкүмәт хәбәрләрен тапшырганда тапшыру программаларын туктату тыела.

19. Элемтә оешмалары, элемтә операторлары һәм телерадиотапшырулар оешмалары хәбәр итү системасын реконструкцияләү һәм техник әзерлектә тоту эшләрен шартнамә нигезендә гамәлгә ашыралар.

20. Халыкка хәбәр итү системасын булдыру, аны тәэмин итү һәм файдалануга даими әзерлектә тоту максатында Башкарма комитет, ТР ГТХМ ның Яр Чаллы шәһәре буенча Идарәсе, Россия ГТХМ ДЯКХ ФЯКХ ЯКХ ның ТР буенча 15 нче ЯКХ һәм «ЯКХ» МБУ белән берлектә түбәндәгеләрне башкаралар:

халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү өчен сөйләм хәбәрләрнең текстларын эшлиләр һәм аларны магнитлы һәм башка мәгълүмат йөрткечләргә яздыруны оештыралар;

хәбәр итү сигналларын һәм сөйләм мәгълүматны тапшыру программаларына кертү өчен телерадиотапшыру объектларында махсус аппаратура урнаштыруны тәэмин итәләр;

тыныч вакытта һәм сугыш вакытында хәбәр итү сигналларын һәм сөйләм мәгълүмат бирү буенча оператив дежур (дежур-диспетчерлык) хезмәтләре әзерлеген оештыралар һәм гамәлгә ашыралар;

элемтә оешмалары, элемтә операторлары, телерадиотапшыру оешмалары белән

берлектә хәбәр итү системаларын тикшерүне, хәбәр итү сигналлары һәм сөйләм мәгълүмат бирү буенча күнекмәләрне планлаштыралар һәм үткәрәләр;

хәбәр итү сигналлары һәм сөйләм мәгълүмат биргәндә элемтә оешмалары, элемтә операторлары, телерадиотапшыру оешмаларының дежур (дежур-диспетчерлык) хезмәтләре белән үзара эшчәнлек тәртибен эшлиләр.

21. Хәбәр итү системасының куллануга даими әзерлектә торуын тәэмин итү максатында элемтә оешмалары, элемтә операторлары һәм телерадиотапшыру оешмалары түбәндәгеләрне башкаралар:

хәбәр итү системасында кулланыла торган хәбәр итү аппаратуралары, элемтә чаралары, элемтә каналларының һәм телерадиотапшыру чараларының техник әзерлеген тәэмин итәләр;

студияләрнең һәм техник элемтә чараларының хәбәр итү сигналлары һәм сөйләм мәгълүмат бирүгә әзерлеген тәэмин итәләр;

Башкарма комитет заявкалары буенча халыкка хәбәр итү өчен билгеләнгән каналлар, элемтә чаралары исемлеген билгелиләр, шулай ук халыкка хәбәр итү өчен сөйләм мәгълүматны магнитлы һәм башка мәгълүмат йөрткечләргә яздыралар.

22. Хәбәр итү системаларын булдыру, камилләштерү һәм файдалануга даими әзерлектә тоту, барлык дәрәҗәләрдә хәбәр итү системасы өчен чаралар запасын булдыру һәм тотуны, хәбәр итүне тәэмин итүгә җәлеп ителгән элемтә оешмалары, элемтә операторлары һәм телерадиотапшыру оешмалары күтәргән чыгымнарны каплауны финанслау Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы — А.Ф. Бареева